| | |
|---|---|
| **СОВЕТ ИМЕНИ ВОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

22.09.2026 № 1

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 июлендәге «Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» №2 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсенең 8 өлеше, 31 маддәсенең 13 өлеше (04.08.2026 елдагы үзгәрешләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 июлендәге «Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» №2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12 маддәсенең 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлаулар үткәрү вакыты муниципаль берәмлекнең халкына аның үткәреләчәге турында хәбәр иткән көннән башлап, иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарганга кадәр, муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның дәвамлылыгы вакыты әлеге проектны бастырып чыгару көненнән башлап, бер айдан күбрәк була алмый.»

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары В. П. Елхов